КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 30 май

г.Казань

№ 495

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре күрсәтү белән тәэмин итү» дәүләт программасын раслау турында» 2019 ел, 3 октябрь, 888 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре күрсәтү белән тәэмин итү» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре күрсәтү белән тәэмин итү» дәүләт программасын раслау турында» 2019 ел, 3 октябрь, 888 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 19 ноябрь, 1048 нче, 2020 ел, 28 гыйнвар, 33 нче; 2020 ел, 26 февраль, 147 нче, 2020 ел, 27 июль, 626 нчы, 2020 ел, 09 ноябрь, 1002 нче, 2020 ел, 01 декабрь, 1078 нче, 2021 ел, 03 февраль, 52 нче, 2021 ел, 23 апрель, 279 нчы, 2021 ел, 25 сентябрь, 916 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре күрсәтү белән тәэмин итү» дәүләт программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программаның 1 бүлегендә:

егерме бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Барысы 2008 – 2018 елларда республикада 49,1 млн.кв.метр гомуми мәйданлы 10,8 мең күпфатирлы йорт ремонтланды. 11 ел эчендә чараларны финанслау күләме 58,8 млрд.сум, шул исәптән милекчеләр акчасы исәбеннән 20,5 млрд.сум тәшкил итте.

Капиталь ремонт үткәрелгән күпфатирлы йортларда яшәүчеләр саны 1,9 млн.кеше тәшкил итә.»;

илле сигезенче абзацта «дәүләт торак күзәтчелеге» сүзләрен «төбәк дәүләт торак контроле (күзәтчелеге)» сүзләренә алмаштырырга;

Программаның 2 бүлегендәге җитмеш тугызынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«төбәк дәүләт торак контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру;»;

«Торак» федераль проекты чараларын гамәлгә ашыру» ярдәмче программасында (алга таба – 3 нче ярдәмче программа):

3 нче ярдәмче программага 1 нче кушымтаның «федераль бюджет» юлындагы 13 графасында «108 820,6» саннарын «168 820,6» саннарына алмаштырырга;

3 нче ярдәмче программаның 2 нче кушымтасына 2 нче таблицадан соң түбәндәге эчтәлекле 3 нче таблица өстәргә:

«3 нче таблица

2022 ел

| Т/с | Муниципаль берәмлек исеме | Капиталь төзелеш объекты исеме / чаралар | Куәте | Җаваплы министрлык, ведомство | Финанслау, мең сум (агымдагы бәяләрдә) | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | барлыгы акча | шул исәптән | |
| | | | | | | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы | җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы |
| 1. | Казан шәһәре | Светофор объектын урнаштырып, Родин һәм Гадел Кутуй урамнары киселешендәге чатны төзекләндерү | 106,47 метр | ТАТКХМ, ДИТИ, ҖҮО | 29 060,0 | 5 521,4 | 23 538,6 |
| 2. | Яр Чаллы шәһәре | «Замелекесье» торак районында төбәк әһәмиятендәге транспорт һәм җәяүлеләр йөри торган магистраль урам (Ш1-Ж урамының дәвамы) | 0,771 км | ТАТКХМ, ДИТИ, ҖҮО | 38 555,7 | 7 325,6 | 31 230,1 |
| 3. | Питрәч муниципаль районы | Татарстан Республикасы Питрәч районының «Усадьба Царево» торак комплексында, 2 500 м$^3$/тәүлектән алып 4 000 м$^3$/тәүлеккә кадәр җитештерүчәнлекне арттырып, хуҗалык-көнкүреш канализациясенең чистарту корылмаларын реконструкцияләү | 4 000 м$^3$/тәүлек | ТАТКХМ, ДИТИ, ҖҮО | 140 804,8 | 26 752,9 | 114 051,9 |
| 2022 ел буенча барысы | | | | | 208 420,5 | 39 599,9 | 168 820,6»; |

«Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәткә капиталь ремонт ясау буенча төбәк программасы чараларын гамәлгә ашыру» ярдәмче программасында (алга таба – 5 нче ярдәмче программа):

5 нче ярдәмче программаның 1 бүлегендәге унбишенче абзацында «15,7» һәм «79,7» саннарын шул ук эзлеклелектә «10,8» һәм «49,1» саннарына алмаштырырга;

5 нче ярдәмче программаның 2 бүлегендәге 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) эксплуатацияләү тасвирнамәләре яхшыртылган озак чыдамлы материалларны кулланып, күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча түбәндәге хезмәтләр күрсәтү һәм (яки) эшләр башкару:

электр, җылылык, газ, су белән тәэмин итү, су чыгару буенча йорт эчендәге инженерлык системаларын ремонтлау яки алыштыру;

лифтларны ремонтлау, алыштыру, модернизацияләү, лифт шахталарын, машина һәм блок урыннарын ремонтлау;

түбә ремонтлау, җилләми торган түбәне җилләнә торган түбә итеп ясау, өй түбәсенә чыгу урыннарын ясау;

күпфатирлы йорттагы уртак мөлкәткә караган подвал урыннарын ремонтлау;

фасадны җылыту һәм ремонтлау;

коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле ресурслар куллануны исәпкә ала торган күмәк (гомумйорт) приборларны һәм мондый ресурсларны (җылылык энергиясе, кайнар һәм салкын су, газ) куллануны җайга салу һәм идарә узелларын кую һәм (яки) алыштыру;

коммуналь ресурсларны һәм коммуналь хезмәтләрне куллануны исәпкә алуның автоматлаштырылган мәгълүмат-үлчәү системаларын урнаштыру;

күпфатирлы йортның фундаментын, шулай ук күтәреп торучы диварларны, түшәмә плитәләрен, балкон һәм башка плитәләрне, күтәреп торучы баганаларны һәм башка әйләнедереп алган күтәреп торучы конструкцияләрне ремонтлау һәм (яки) ныгыту;

төзелеш контролен гамәлгә ашыру;

проект документларына дәүләт экспертизасын әзерләү һәм үткәрү (проект документларын әзерләү шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә кирәк булган очракта), капиталь ремонтның смета кыйммәтен билгеләү дөреслегенә тикшерү үткәрү;

күпфатирлы йорттагы подъездларны, күпфатирлы йорттагы аерым милекчеләрнеке булмаган һәм бүлмәләр милекчеләренең социаль-көнкүреш ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен билгеләнгән башка бүлмәләрне ремонтлау;

вентиляция каналларын һәм төтен юлларын ремонтлау;

күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәт составына керми торган, күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәт составына керә торган конструкцияләрне һәм инженерлык системаларын капиталь ремонтлау эшләрен башкарганда ремонтлана (алыштырыла) торган конструкцияләр һәм инженерлык системаларының технологик һәм конструктив үзенчәлекләре нәтиҗәсендә сүтелгән яки җимерелгән мөлкәт өлешен торгызу, шулай ук ремонт эшләре тәмамланганнан соң төзекләндерү;

2014 елның 1 июненә кадәр куелган (алыштырылган) күпфатирлы йортлардагы коммуналь ресурсларны куллану исәбен алуның күмәк (гомумйорт) җайланмаларын кую (алыштыру);

күпфатирлы йортның янгыннан саклау системасын ремонтлау;»;

«Архитектура, шәһәр төзелеше, төзелеш, төзелеш материаллары сәнәгате өлкәсендә, торак өлкәсендә һәм коммуналь хуҗалыкта дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру» ярдәмче программасында (алга таба – 8 нче ярдәмче программа):

8 нче ярдәмче программаның 2 бүлегендә:

1 нче таблицадан соң утыз беренче абзацта «Татарстан Республикасында дәүләт торак күзәтчелеге» сүзләрен «Төбәк дәүләт торак контроле (күзәтчелеге)» сүзләренә алмаштырырга;

1 нче таблицадан соң утыз өченче абзацта «төбәк дәүләт торак күзәтчелеге» сүзләрен «төбәк дәүләт торак контроле (күзәтчелеге)» сүзләренә алмаштырырга;

8 нче ярдәмче программаның 2 бүлегендәге алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«төбәк дәүләт торак контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру;»;

8 нче ярдәмче программаның 4 бүлегендәге өченче абзацында «Республика дәүләт торак күзәтчелеген гамәлгә ашыру» сүзләрен «Төбәк дәүләт торак контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру» сүзләренә алмаштырырга;

8 нче ярдәмче программага кушымтада:

«Архитектура, шәһәр төзелеше, гражданлык һәм сәнәгать төзелеше, торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә ТАТКХМның[1] гомумпрограмма эшчәнлеге» юлының «Төзелеш предприятиеләренең гомуми санында табыш бирми торган төзелеш предприятиеләре өлеше, %» өстәмә юлында:

8 графада «23,0» саннарын «23,5» саннарына алмаштырырга;

9 графада «22,0» саннарын «23,0» саннарына алмаштырырга;

10 графада «21,0» саннарын «22,5» саннарына алмаштырырга;

«Төбәк дәүләт торак күзәтчелеген гамәлгә ашыру» юлының 1 графасында «күзәтчелеген» сүзен «контролен (күзәтчелеген)» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры — А.В.Песошин